# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Җир өчен түләү турында
/1993 елның 4 мартындагы редакциясендә/

## I БҮЛЕК

## Төп төшенчәләр

I статья. Татарстан Республикасында җирдән файдалану түләүле. Түләүнең төрләре даими - җир салымы, аренда түләве, шулай ук бер мәртәбә генә түләнә торганы да була, моңа җир кишәрлекләрен файдалануга һәм биләүгә тапшырылганда, шулай ук шәһәрнең яисә торак пунктның инженерлык һәм табигатьне саклау төзелмәләрен торгызу өчен түләүләр керә.

Арендаторлардан тыш, җир милекчеләренә, җир биләүчеләргә һәм җирдән файдаланучыларга җир салымы салына. Арендага тапшырылган җирләр өчен аренда түләве алына.

Җир кишәрлекләрен сатып алу өчен, шулай ук банк кредиты хисабына җирне бурычка алу өчен җирнең норматив хакы билгеләнә.

2 статья. Җир өчен түләү кертүнең максаты-җирдән нәтиҗәле файдалануга, саклауга һәм яңа җирләрне үзләштерүгә, туфракның уңдырышлылыгын күтәрүгә, төрле сыйфатлы җирләрдә хуҗалык итүнең иҗтимагый-икътисадый шартларын тигезләүгә, тиешле төзелмәләрнең

үсешен тәэмин итүгә, әлеге гамәлләрне финанслауның махсус фондларын төзүгә этәргеч тудырудан гыйбарәт.

3 статья. Җир салымының күләме җир милекчеләренең, җир биләүчеләрнең һәм җирдән файдаланучыларның хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләренә бәйле булмый һәм бер елга бер берәмлек җир мәйданы өчен тотрыклы түләүләр рәвешендә билгеләнә.

## II БҮЛЕК

### Авыл хуҗалыгы җирләре өчен түләү

4 статья. Колхозлардан, совхозлардан, крестьян /фермер/ хуҗалыкларыннан, хуҗалыкара предприятиеләрдән һәм оешмалардан, кооперативлардан һәм авыл хуҗалыгының башка предприятиеләреннән җир өчен түләү генә алына, салымның башка барлык төрләре аларга карата кулланылмый.

Авыл хуҗалыгына карамаган эшчәнлектән 25 проценттан да артыграк керем алган предприятиеләргә әлеге кагыйдә кагылмый.

5 статья. Авыл хуҗалыгы җирләренә җир салымы аларның составына, бонитетына /сыйфатына/, мәйданына һәм кайда урнашуларына карап билгеләнә.

Бер гектар сөрүлек җирләрдән, күпъеллык үсемлекләрдән, печәнлекләрдән һәм көтүлекләрдән административ районнар /шәһәрләрдәге районнардан тыш/ буенча, әлеге җирләрнең кадастр бәяләмәсенә һәм урнашуларына карап, салымның уртача күләме билгеләнә һәм Татарстан Республикасы Югары Советы тарафыннан агымдагы ел бюджеты белән бергә раслана.

Халык депутатларының шәһәр һәм район Советлары /шәһәрләрдәге районнардан тыш/, бер гектар сөрүлекләрдән, күпъеллык үләннәрдән, печәнлекләрдән, көтүлекләрдән,салымның уртача күләменнән һәм әлеге

җирләрнең кадастр бәяләмәсеннән чыгып, шушы Законның 4 маддәсендә күрсәтелгән һәр җир биләүче өчен җир салымы күләмен аерым билгелиләр һәм раслыйлар.

Авыл хуҗалыгында файдаланылучы җирләр өчен җир салымы күләмен билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты әзерли һәм раслый.

6 статья. Авыл торак пунктлары чикләрендәге яисә шәхси һәм күмәк бакчачылык, терлекчелек, шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, шәхси торак төзелеше алып бару өчен гражданнарга бирелгән бакчачылык ширкәтләре чикләрендәге җирләр өчен, шулай ук башка максатларда файдалану өчен гражданнарга, юридик затларга һәм авыл җирендә урнашкан дача төзелеше кооперативларына бирелгән җирләр өчен салым җир кишәрлегенең барлык мәйданыннан Татарстан Республикасы Югары Советы раслаган күләмнәр буенча билгеләнә, әмма ул иң кечкенә хезмәт хакының 0,001 процентыннан артмаска тиеш.

Печәнлекләргә, көтүлекләргә дип гражданнарга бирелгән җирләр өчен салым авыл хуҗалыгында файдаланылучы җирләр өчен түләүләр күләменә карап билгеләнә.

Халык депутатларының шәһәр һәм район /шәһәрләрдәге районнардан тыш/ Советларына, әлеге статьяда күрсәтелгән җир кишәрлекләре урнашуының уңайлы шартларын исәпкә алып, җир салымын ике тапкырдан да артмаган күләмнәргә кадәр күтәрү хокукы бирелә.

## III БҮЛЕК

## Авыл хуҗалыгына карамаган җирләр өчен түләү

7 статья. Милкендә, биләвендә яисә кулланылышында җир кисәкләре булган һәр предприятиедән, оешмадан, учреждениедән һәм гражданнан шәһәрләрдәге, эшчеләр поселокларындагы җирләр өчен салым шәһәр җирләре өчен билгеләнгән күләмнәрдә алына.

Шәһәрләрдә һәм башка торак пунктларында халык депутатларының тиешле Советлары карары нигезендә җир кисәкләрен даими кулланылышка һәм биләүгә бирү белән бәйле, инженерлык һәм табигатьне саклау төзелмәләрен торгызу өчен кирәкле чыгымнарны каплаучы түләү бер мәртәбә алына. Даими кулланылышка һәм биләүгә җир кисәкләре бирүдән килгән һәм шәһәрләрнең, поселокларның инженерлык һәм табигатьне саклау төзелмәләрен торгызу өчен билгеләнгән акча бюджеттан тыш фондка керә һәм билгеләнүенә карап тотыла.

8 статья. Шәһәр җирләре өчен салым шәһәрләрнең категорияләре буенча, аларның статусын, иҗтимагый-мәдәни мөмкинчелекләре дәрәҗәсен, тарихи һәм ял итү өчен әһәмиятен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Югары Советы раслаган күләмнәрдә исәпләнелә, монда авыл хуҗалыгында файдаланылучы җирләр, шулай ук шәхси ярдәмче хуҗалыклар, торак фонды, шәхси гаражлар биләүче җирләр керми.

Халык депутатларының шәһәр Советлары салымның уртача күләмнәрен шәһәрнең кайда урнашуына һәм шәһәр төзелеше өчен территория әһәмиятенең төрле зоналарына карап билгелиләр. Зоналарның чикләре территориянең икътисадый бәяләмәсенә һәм шәһәрләрнең төп /генераль/ планына карап билгеләнә.

Салым салына торган мәйданнарга төзелеш һәм корылмалар урнашкан җирләр, аларны тоту өчен кирәкле җирләр, шулай ук санитария ягыннан яклаучы, техник һәм башка зоналар кертелә.

Шәһәрләрдәге һәм поселоклардагы җир салымы күләмнәрен билгеләү тәртибе Татарстан Республикасының Министрлар кабинеты тарафыннан әзерләнә һәм раслана.

Торак фонды /дәүләт, иҗтимагый, кооператив, шәхси/, шәхси гаражлар биләгән җирләр өчен, шулай ук авыл хуҗалыгы максатларында файдаланылучы җирләр, шәхси ярдәмче хуҗалык җирләре, шәһәр һәм поселок чикләрендә урнашкан күмәк бакчачылык җирләре өчен җир салымы Татарстан Республикасы Югары Советы раслаган күләмнәрдә исәпләнелә.

9 статья. Торак пунктларыннан читтә урнашкан сәнәгать /карьерларны һәм җитештерү эшчәнлеге нәтиҗәсендә бозылган территорияләрне, суэлектр-станцияләренең сусаклагычларын да кертеп/ җирләре өчен, элемтә һәм транспорт, радиотапшырулар һәм телевидение, информация һәм галәм тәэминаты җирләре өчен, хакимият һәм идарә органнары, Кораллы көчләрнең, эчке һәм тимер юл гаскәрләренең, галәм системаларының эшчәнлеген тәэмин итүгә бирелгән җирләр өчен салым авыл хуҗалыгы җирләренә билгеләнгән салымның өчләтелгән күләмендә түләнә.

Торак пунктларыннан читтә урнашкан полигоннар /хәрбиләреннән гайре/ һәм аэродромнар биләгән җирләр өчен салым шушы территориянең бер гектар сөрүлек җире өчен билгеләнгән салымның уртача күләмнәренә карап билгеләнә.

Әлеге статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән республика буйсынуындагы шәһәрләрнең шәһәр яны зоналарында һәм курортларның саклана торган зоналарында урнашкан җирләрдән файдаланган өчен, шәһәрнең статусына һәм территориянең ял итү өчен әһәмиятенә карап, Татарстан Республикасы Югары Советы раслаган арту коэффициентлары билгеләнә.

10 статья. Торак пунктларыннан читтә урнашкан, су белән капланган һәм капланмаган, хуҗалык эшчәнлеге яисә ял итү максатларында бирелгән су фонды җирләре өчен салым административ районындагы авыл хуҗалыгы җирләре салымының уртача күләмнәреннән чыгып салына.

11 статья. Агач әзерләү өчен кулланылышка бирелүче урман фонды җирләре өчен үзләштерелгән урман мәйданнарының һәр берәмлегеннән тамыры белән сатылучы агач бәясенең биш проценты күләмендә салым алына.

Урман фондына керүче авыл хуҗалыгы җирләре өчен салым авыл хуҗалыгының шундый ук җирләренә билгеләнгән салым күләмнәреннән чыгып салына.

Билгеләнгән тәртипкә ял итү максатларында бирелгән урман фонды җирләре өчен салым бу мәйданнарда агачка билгеләнгән хакның биш процентгы күләмендә салына, курорт зоналары өчен күләмнәрнең артуы күздә тотыла.

## ІУ БҮЛЕК

### Җир өчен түләү буенча ташламалар

12 статья. Законнар нигезендә һәм билгеләнгән нормативлар чикләрендә бирелгән җирләр өчен җир салымы түләүдән түбәндәге физик һәм юридик затлар тулысынча азат ителә:

1/ тыюлыклар, милли һәм дендрология парклары, ботаника бакчалары;

2/ авыл хуҗалыгына һәм урман хуҗалыгына караган фәнни оешмалар, уку-тәҗрибә, тәҗрибә һәм тикшерену хуҗалыклары, фәнни тикшерену учреждениеләре һәм уку йортлары турыдан-туры фәнни һәм укыту максатларында файдалана торган җир кишәрлекләре өчен, шулай ук колхозлар, совхозлар, башка авыл хуҗалыгы һәм урман хуҗалыгы предприятиеләре авыл хуҗалыгы һәм урман хуҗалыгы культураларының сортларын сынарга бирелгән җирләр өчен;

3/ дәүләт бюджеты исәбенә яисә профсоюзлар исәбенә финанслаңучы мәдәният, сәнгать һәм кинематография, мәгариф, сәламәтлек саклау, физик тәрбия һәм спорт учреждениеләре, шифаханәләр, балалар учреждениеләре, профилакторийлар, укучылар өчен сәламәтләндерү җәйләүләре, турист һәм спорт-савыктыру комплекслары, шулай ук табигатьне, тарих һәм мәдәният ядкярләрен саклау буенча дәүләт

органнары, дини берләшмәләр, аларның тарих, мәдәният һәм архитектура ядкярләре буларак дәүләт тарафыннан саклана торган гыйбадәт кылу биналары;

4/ куллануның башТагы I5 елында яңадан торгызуны таләп итүче бозылган җирләрне авыл хуҗалыгы ихтыяҗлары өчен куллануга алган предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, шулай ук гражданнар;

5/ Бөек Ватан сугышында катнашучылар, элеккеге СССРны саклау буенча хәрби гамәлләрдә катнашкан, хәрәкәттәге армия составына кергән хәрби частьләрдә, штабларда һәм учреждениеләрдә хезмәт иткән хәрбиләр, элеккеге партизаннар һәм шуларга тиңләштерелгән гражданнар категорияләре;

6/ гарипләр, шулай ук законнар нигезендә керемгә салымнан һәм башка барлык салымнардан тулысынча азат ителгән гражданнар, авыл җирендә яшәп пенсиягә чыккан ялгыз пенсионерлар;

7/ Чернобыль афәте нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучылар;

8/ урман торгызу, урман үрчетү, урманнарны саклау һәм яклау буенча эшләр башкаручы урман хуҗалыгы предприятиеләре;

9/ торак пунктларның һәм җирле хуҗалыкның гомуми кулланылыштагы җирләреннән файдаланучылар;

I0/ гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларыннан һәм юл корылмаларыннан файдаланучы оешмалар.

Беренче тапкыр крестьян /фермер/ хуҗалыклары оештыручы гражданнар аларга җир кишәрлекләре бирү мизгеленнән алып баштагы биш ел дәвамында җир өчен түләүдән азат ителәләр.

I3 статья. Татарстан Республикасы Югары Советы аерым административ районнарның /шәһәрләрдәге районнардан гайре/ авыл хуҗалыгы җирләре өчен, авыл хуҗалыгында районның җитештерү көчләре үсешенең дәрәҗәсенә бәйле рәвештә, җир салымы күләмнәрен киметә һәм ташламалар билгели ала.

14 статья. Халык депутатларының авыл, поселок, район, шәһәр Советлары, Татарстан Республикасы Югары Советы билгеләгән ташламаларны исәпкә алып, билгеле бер вакытка тулысынча яисә өлешчә салымнардан азат итү рәвешендәге җир салымын алу буенча ташламалар билгеләргә, түләүләрне кичектерергә һәм түбәндәгеләр өчен җир салымы күләмнәрен киметергә хаклылар:

- кулланучының гаебе булмыйча, табигый бәла-казалар һәм башка афәтләр нәтиҗәсендә җир биләүче һәм җирдән файдаланучы шактый гына матди зыян күргән очракларда, юридик затлар һәм гражданнар өчен;

- күп балалы, аз керемле һәм яшь гаиләләр өчен;

- җәмгыяте хәйрия оешмалары өчен.

Эш башкару проектында каралган чорга авыл хуҗалыгы җирләрен үзләштерү чорында булган җир кишәрлекләре өчен предприятиеләрдән, учреждениеләрдән, оешмалардан һәм гражданнардан җир салымы һәм җир өчен аренда түләве алынмый.

Әлеге Законның 13, 14 статьяларында каралган ташламалар халык депутатларының тиешле Советлары карамагында калган җир салымы күләме чикләрендә бирелә.

## У БҮЛЕК

### Җир өчен түләүне билгеләү һәм алу тәртибе

15 статья. Җир кишәрлекләрен милекчелеккә, биләүгә яисә алардан файдалануга /арендалауга/ хокукны раслаучы документ җир өчен салымны һәм аренда түләвен билгеләү өчен нигез булып тора.

16 статья. Юридик затлар түли торган җир салымы турыдан-туры бу затларның үзләре тарафыннан исәпләнелә.

Юридик затлар һәр җир кишәрлеге буенча агымдагы елда үзләренә тиешле салым исәп-хисабын 1 июльдән дә соңга калмыйча салым органнарына тапшыралар.

Яңа бирелгән җир кишәрлекләре буенча салым исәп-хисабы аларны

биру мизгеленнән башлап бер ай дәвамында тапшырыла.

Гражданнарга җир салымы дәүләтнең салым хезмәте органнары тарафыннан исәпләнелә, алар ел саен I августтан да соңга калмыйча салым түләү турында гражданнарга түләү кәгазе тапшыралар.

Берничә юридик затның яисә гражданның аерым кулланылышында булган корылмага хезмәт күрсәтү өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә җир салымы, аларның һәрберсенең кулланылышында булган корылма мәйданына туры китереп, һәр кайсына аерым-аерым салына.

Берничә юридик затның яисә гражданның гомуми милегендә булган корылмага хезмәт күрсәтү өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә җир салымы һәр милекчегә аларның бу корылмадагы өлешләре күләмендә салына.

I7 статья. Салым түләүчеләрне исәпкә алу һәм салымны исәпләү I июньгә кадәрге халәт буенча башкарыла.

Юридик затлардан һәм гражданнардан җир салымы аларга җир кисәкләре бирелгән айдан соң килүче айдан башлап исәпләнә.

Дәүләтнең салым инспекцияләре салым түләүчеләрне исәпкә алып баралар, салым исәпләүнең һәм аны түләүнең дөреслеген тикшереп торалар.

Салым суммалары I5 сентябрьдән һәм I5 ноябрьдән дә соңга калмыйча тигез өлешләрдә түләнә. Билгеләнгән вакытта салым түләнмәгән очракта һәр кичектерелгән көн өчен түләнми калган салым суммасының 0,2 проценты күләмендә пени салына, әмма ул еллык салым суммасының 200 процентыннан да артмаска тиеш.

Җирле шартларны исәпкә алып, халык депутатлары Советлары салым түләүнең башка вакытларын да билгели ала.

Салым салуның дөреслеген яңадан карау үткән ике ел өчен генә рөхсәт ителә.

I8 статья. Җир өчен түләүләр халык депутатлары тиешле җирле Советларының махсус бюджет хисапларына кертелә:

авыл торак пунктлары чикләрендәге җирләр һәм алар карамагына бирелгән башка җирләр өчен - халык депутатларының авыл Советларына;

шәһәр /поселок/ чикләрендәге җирләр һәм алар карамагына бирелгән башка җирләр өчен-халык депутатларының поселок, шәһәр Советларына;

халык депутатларының авыл, поселок һәм шәһәр Советлары карамагына бирелгән җирләрдән гайре, административ район чикләрендәге җирләр өчен - халык депутатларының район Советларына.

19 статья. Административ районнарның авыл хуҗалыгы җирләре өчен, шулай ук шәһәр һәм поселок җирләре өчен җир салымы һәм аренда түләве суммаларының 30 проценты үзәкләштерү тәртибендә әлеге Законның 23 статьясында каралган гамәлләрне үтәү өчен Татарстан республика бюджетының махсус хисабына күчерелә.

20 статья. Предприятиеләргә, учреждениеләргә, оешмаларга бирелгән җир кишәрлекләренә салымны дөрес исәпләү һәм үз вакытында түләү өчен җаваплылык аларның җитәкчеләренә йөкләнә.

21 статья. Җир өчен аренда түләвен керту күләме, шартлары һәм вакытлары шартнамәдә билгеләнә. Авыл хуҗалыгына караган җирләрне арендалаганда аренда түләвенең күләме арендалана торган кишәрлекләргә салынган җир салымы суммасыннан артмаска тиеш.

22 статья. Җир өчен аренда түләве мәсьәләләре буенча килеп чыккан бәхәсләр үз вәкаләтләре чикләрендә Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды яисә суд тарафыннан карала, ә җир салымына кагылышлы мәсьәләләр буенча бәхәсләр Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнар нигезендә карала.

## УI__БҮЛЕК

### Җир_өчен_түләүләрдән_кергән_акчаларны_куллану_

23_статья. Җир салымы һәм аренда түләве тиешле бюджетларның керемнәрендә һәм чыгымнарында аерым юл рәвешендә карала һәм бары тик түбәндәге максатларда гына кулланыла:

- җир төзелеше буенча, җир кадастры, мониторинг кертү, җирләрне саклау һәм аларның уңдырышлылыгын торгызу, яңа җирләр үзләштерү буенча гамәлләрне финанслауга, җирдән файдаланучының әлеге максатларда тотылган чыгымнарын каплауга һәм күрсәтелгән гамәл өчен бирелгән ссудаларны, алардан файдаланган өчен процентларны түләүгә. Әлеге гамәлләргә бирелгән акча тиешле нормативлар буенча тотыла;

- территорияне инженерлык ягыннан һәм җәмгыяви төзекләндерү.

Авыл хуҗалыгы җирләре өчен салымнан һәм аренда түләвеннән килгән акча әлеге статьяда күрсәтелгән максатларда авыл хуҗалыгы җирләре .. милекчеләренең, җир биләүчеләренең һәм кулланучыларының ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен генә тотыла.

Ел дәвамында җир өчен түләүләрдән тотылмый калган акчалар кире алынмый һәм киләсе елда кирәкле максатларда гына кулланыла.

## УП__БҮЛЕК

### Җирнең_норматив_хакы

24_статья. Җирнең норматив хакы - билгеле бер сыйфатлы һәм билгеле бер урында урнашкан кишәрлекнең хакын билгеләүче күрсәткеч, ул үзкыйммәтен кире кайтаруның хисап чорына туры килүче керемнәрдән чыгып исәпләнә.

Җирнең норматив хакы шул ук вакытка билгеләнгән җир салымы

куләменнән түбәнрәк була алмый.

Җирнең норматив хакы җирне милеккә тапшырганда, мирас итеп биргәндә, җиргә күмәк-өлеш милекчелеге билгеләгәндә, бүләк иткәндә һәм җир кишәрлеген банк кредиты хисабына бурычка алганда, шулай ук шәһәрләрдә һәм поселокларда инженерлык һәм табигатьне саклау төзелмәләрен торгызу өчен бер тапкыр бирелә торган түләүләрне билгеләгәндә җир буенча үзара мөнәсәбәтләрне икътисадый җайга салу өчен кертелә.

25 статья. Җирнең норматив хакы Татарстан Республикасы Югары Советы тарафыннан билгеләнә. Җирнең норматив хакын ачыклау тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

## ӨЧ БҮЛЕК

## "Җир өчен түләү турында" Татарстан Республикасы Законын бозган өчен җаваплылык

26 статья. Җир өчен түләүне билгеләү, алу һәм куллану буенча әлеге Законны бозу рәвешендә башкарылган гамәлләр башкарылган мизгеленнән үк гамәлдән чыгарылган дип санала.

Алда күрсәтелгән гамәлләрне башкарган, шулай ук әлеге Законның башка төшенчәләрен бозган затлар Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнар нигезендә административ һәм җинаять җаваплылыгына тартылалар.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1992 елның 30 сентябре
№ 1767-XII